КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 246

Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 246 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә республика дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 декабрь, ФЗ-443 нче Федераль закон (алга таба – ФЗ-443 нче Федераль закон), «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 ел, 20 декабрь, ТРЗ-103 нче Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны (алга таба – төбәк дәүләт тикшерүендә тоту) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне билгели.

2. Бу Тәртиптә түбәндәге төп төшенчәләр һәм терминнар кулланыла:

вәкаләтле башкарма хакимият органы – юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы;

вәкаләтле җирле үзидарә органнары – юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары;

тикшерүдә тоту объектлары – вәкаләтле башкарма хакимият органы, вәкаләтле җирле үзидарә органнары, алар карамагындагы ФЗ-443 нче Федераль законның 8 статьясы нигезендә күрсәтелгән вәкаләтле оешмалар.

3. Төбәк дәүләт тикшерүендә тоту максатлары – Татарстан Республикасы территориясендә төбәк яки муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә ФЗ-443 нче Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) бозуларны кисәтү, ачыклау һәм туктату.

4. Төбәк дәүләт тикшерүендә тоту Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Төбәк дәүләт тикшерүендә тоту – ул юл хәрәкәтен оештыру нәтиҗәлелеген тәэмин итүне бәяләү буенча, шул исәптән төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру мониторингын гамәлгә ашыру буенча, фактtagы юл хәрәкәте параметрларының юл хәрәкәтен оештыру

документларында юл хәрәкәтен һәм юл хәрәкәте нәтиҗәлелеген характерлый торган параметрлар буларак билгеләнгән параметрларга туры килүен бәяләү буенча, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә, муниципаль берәмлекләр территорияләрендә юл хәрәкәтен оештыру документлары белән күздә тотылган карарларда юл хәрәкәтен оештыру нәтиҗәлелеген бәяләү буенча тикшерүдә тоту объектлары эшчәнлеген тикшерүдә тоту, шулай ук тикшерүдә тоту объектлары тарафыннан юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге законнарны бозуларны ачыклау һәм туктату дигәнне аңлата.

6. Төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда Министрлыкның вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары, вәкаләтле башкарма хакимият органнары, вәкаләтле җирле үзидарә органнары, экспертлар, эксперт оешмалары, юл хәрәкәтен оештыру һәм мониторинглау өлкәсендә вәкаләтле оешмалар, юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр, физик затлар, үз-үзен җайга салучы оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

7. Төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры;

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрының юл хуҗалыгы мәсьәләләре өчен җавап бирүче урынбасары;

Министрлыкның автомобиль юллары бүлеге башлыгы, төп киңәшчесе, төп консультанты.

## II. Төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны үткәрүгә карата төп таләпләр

8. Төбәк дәүләт тикшерүендә тоту документларга тикшерүләр һәм (яки) барып тикшерүләр үткәрү рәвешендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр оештыру һәм үткәрү, мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын, вәкаләтле башкарма хакимият органнары, вәкаләтле җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итмичә, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән күздә тотылган ачыкланган бозуларны кисәтү һәм (яки) алар салган зыяннарны бетерү буенча чаралар кабул итмичә гамәлгә ашырыла торган тикшерүдә тоту чараларын оештыру һәм үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

9. Вәкаләтле башкарма хакимият органына карата төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны оештырганда һәм гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә карата, ФЗ-443 нче Федераль законның 20 статьясы белән билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 ел, 6 октябрь, ФЗ-184 нче Федераль законның (алга таба – ФЗ-184 нче Федераль закон) $29^2$ статьясы нигезләмәләре кулланыла.

10. Вәкаләтле җирле үзидарә органнарына карата төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны оештырганда һәм гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә карата, ФЗ-443 нче Федераль законның 20 статьясы белән билгеләнгән тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Россия

Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль законның (алга таба – ФЗ-131 нче Федераль закон) 77 статьясы нигезләмәләре кулланыла.

11. Вәкаләтле җирле үзидарә органнары, вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан ФЗ-184 нче Федераль закон, ФЗ-131 нче Федераль закон һәм ФЗ-443 нче Федераль закон белән җайга салынмаган өлештә төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны оештырганда һәм гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә карата «Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон (алга таба – ФЗ-294 нче Федераль закон) нигезләмәләре кулланыла.

12. Тикшерүләр предметы – тикшерүдә тоту объектлары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, шул исәптән түбәндәгеләрне үтәү:

ФЗ-443 нче Федераль законның 10 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә билгеләнгән юл хәрәкәтенең төп параметрларын билгеләү тәртибен;

ФЗ-443 нче Федераль законның 5 статьясындагы 1 нче пунктның 2 өлеше нигезендә билгеләнгән юл хәрәкәтен мониторинглау тәртибен;

юл хәрәкәтен оештыруга бәйле булган һөнәрләр һәм вазыйфалар исемлеген һәм ФЗ-443 нче Федераль законның 5 статьясындагы 1 нче пунктның 10 өлеше нигезендә аларга карата билгеләнгән квалификация таләпләрен;

ФЗ-443 нче Федераль законның 5 статьясындагы 1 нче пунктның 5 өлеше нигезендә билгеләнгән юл хәрәкәтен оештыру документларына карата таләпләрне;

ФЗ-443 нче Федераль законның 12 статьясы нигезендә билгеләнгән гомуми файдаланудагы парковкага карата таләпләрне;

ФЗ-443 нче Федераль законның 13 статьясы нигезендә билгеләнгән түләүле парковкага карата таләпләрне;

ФЗ-443 нче Федераль законның 14 статьясы нигезендә билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын урнаштырганда юл хәрәкәтен оештыруга карата таләпләрне;

ФЗ-443 нче Федераль законның 11 статьясы нигезендә билгеләнгән юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү буенча таләпләрне.

13. Төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырыганда административ процедуралар вакытлары һәм эзлеклелеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары нигезендә эшләнә һәм раслана торган административ регламент белән билгеләнә.

14. Бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

тикшерү үткәрү турындагы боерык чыкканнан соң, тикшерүдә тоту объектларыннан кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны соратып алырга, барып тикшерү үткәргәндә тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган документларны һәм (яки) мәгълүматны бирүне таләп итәргә, әгәр дә документларны тикшерү үткәрү барышында мондый документлар һәм (яки) мәгълүмат алар тарафыннан бирелмәгән булса;

ачыкланган бозуларны бетерүне тикшерүдә тоту, кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, физик яки юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә мөмкин булган зыян салуны кисәтү, булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча чаралар, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки аларның ведомство буйсынуындагы һәм әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче оешмалардан законнар белән билгеләнгән вакытларда, шул исәптән электрон рәвештә соратырга һәм алырга;

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрының тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен һәм хезмәт таныклыгын күрсәтеп, тикшерү чараларын гамәлгә ашыру максатларында кирәкле мәгълүматны, документларны тоткарлыксыз алырга, шулай ук төбәк дәүләт тикшерүендә тотуны гамәлгә ашыру кысаларында кирәкле тикшерүләр, үлчәүләр һәм башка чаралар үткәрергә;

фотога һәм видеога төшерү, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән башка рөхсәт ителгән ачыкланган бозулар буенча дәлилләр алу һәм аларны теркәү ысулларын кулланырга;

тикшерүдә тоту объектларына, ачыкланган бозуларны бетерү вакытларын күрсәтеп, аларны бетерү турында һәм (яки) кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә, физик яки юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә зыян салуны булдырмау, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнар белән күздә тотылган башка чараларны үткәрү турында күрсәтмәләр бирергә;

төбәк дәүләт тикшерүендә тоту барышында ачыкланган бозуларга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрергә.

15. Бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар тикшерүләр үткәргәндә ФЗ-184 нче Федераль законның $29^2$ статьясы, ФЗ-131 нче Федераль законның 77 статьясы, ФЗ-294 нче Федераль законның 15 һәм 18 статьялары белән билгеләнгән чикләүләрне һәм йөкләмәләрне үтәргә, шулай ук үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җавап бирергә хокуклы.

16. Бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.